**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 9 июль № 503

г. Казань

«Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының Төбәк автоматлаштырылган мәгълүмат-идарә итү системасы дирекциясе» дәүләт учреждениесенең исемен үзгәртү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының Төбәк автоматлаштырылган мәгълүмат-идарә итү системасы дирекциясе» дәүләт учреждениесенең исемен «Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының Төбәк автоматлаштырылган мәгълүмат-идарә итү системасы дирекциясе» дәүләт бюджет учреждениесенә (алга таба – Дирекция) үзгәртү турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Дирекцияне гамәлгә куючы вазыйфаларын һәм вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы башкара, дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына Дирекция уставына билгеләнгән тәртиптә тиешле үзгәрешләрне кертергә.

4. Дирекциянең дәүләт хезмәтләрен күрсәтүгә (эшләрен башкаруга) дәүләт йөкләмәсен үтәвен финанслар белән тәэмин итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләренә карата дәүләт йөкләмәсен формалаштыру һәм аның үтәлешен финанслар белән тәэмин итү тәртибе турында» 2010 ел, 29 апрель, 308 нче карары нигезендә гамәлгә ашырыла, дип билгеләргә.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\503.docx